Балалар өчен Изге Язма

тәкъдим итә

# Аллаһы дөньяны кайчан бар иткән





Автор: Edward Hughes
Рәсемнәр: Byron Unger; Lazarus
Alastair Paterson
Кемнәр өчен: Bob Davies; Tammy S.
Тәрҗемә ителде: www.christian-translation.com
Гамәлгә ашырылды: Bible for Children
www.M1914.org

BFC
PO Box 3
Winnipeg, MB R3C 2G1
Canada

©2020 Bible for Children, Inc.
Лицензия: Сезнең бу хикәят текстын, сату хокукыннан башка гына, күчермә итеп яки бастырып алу хокукыгыз бар.

Безне кем бар иткән? Изге Язма, Аллаһы Сүзе, кешелек тормышының ни рәвешле башланып китүе хакында сөйли. Борын-борын заманда Раббыбыз иң беренче кешене яралта һәм аны Адәм дип атый. Раббы Алла адәмне туфрактан яралта һәм аңа тереклек сулышы өрә. Адәм әнә шулай җан иясе була. Ул Гадән исемле бик ямьле бер бакчада пәйда була.



Адәмне яралтыр алдыннан, Раббы Алла бик гүзәл, могҗизалар белән тулган дөнья барлыкка китерә. Таулар һәм киң далалар, хуш исле чәчәкләр һәм биек булып үсә торган агачлар, оча торган кошларны һәм безелдәвек бал кортларын, суда йөзүче балыкларны һәм шуышып йөрүче



хәшәрәтләрне яралта. Тәхкыйкъ ки, Раббы Алла бөтен нәрсәне бар итүче.

Иң әүвәл, Раббы Алла тирә-юнебезне яралтыр алдыннан, Җир йөзе әле сурәтсез, буп-буш – төпсез упкын, караңгылык эченә чумган була. Анда кешеләр дә, урыннар да, әйберләр дә булмый. Якты да, караңгы да булмый. Өске һәм аскы өлеше дә күренми. Кичәгесе дә, иртәгәсе дә юк. Фәкать Раббы Алла гына була. Шулай итеп Раббы Алла Җир йөзенә тереклек сулышы өрә башлый!



Иң әүвәл Аллаһы күкне һәм җирне яралта.

Ә Җир йөзе әле сурәтсез, буп-буш була. Төпсез упкын йөзендә караңгылык кына чагыла. Шунда Аллаһы: “Яктылык булсын!” – дип боера.



Һәм яктылык пәйда була. Раббы Алла яктылыкны – “көн”, караңгылыкны “төн” дип атый. Кич була да таң ата – беренче көн үтеп китә.



Икенче көнне Раббы Алла гөмбәз астындагы суларны океан, диңгез һәм күл итеп аера. Өченче көнне: “Коры туфраклы ялан калкып чыксын!” - дип боера, һәм нәкъ шулай була.



Туфрактан яшеллек, чәчәкләр, куаклыклар һәм агачлар барлыкка килсен, дип тә боера Аллаһы. Һәм нәкъ шулай була.

Кич җитә дә таң ата –
өченче көн үтеп китә.



Шуннан Аллаһы Кояш белән Айны, беркем дә санап бетерә алмаслык санда йолдызларны яралта.  Кич җитә дә таң ата – дүртенче көн үтеп китә.





Алга таба Аллаһы диңгез ияләрен, балыкларны һәм кошларны барлыкка китерә. Бишенче көндә ул зур кылычбалык, нәни сардина балыкларын, озын аяклы тәвә кошларын һәм вак кына колибри кошларын ералта. Җир суларын җанландыру өчен Раббы Алла барлык төрдәге балыкларны яралта, җирдә, диңгездә һәм күктә яшәү өчен барлык төр кошларны барлыкка китерә. Кич була да таң ата – бишенче көн узып китә.



Шуннан соң Аллаһы: “Җир йөзе үзендә төрле токымдагы җан иярләрен – кыргый хайваннарны, терлек һәм хәшәрәтләрне булдырсын!” - дип боера. Анда җирне дер селкетә торган филләр һәм тынгысыз кондызлар, наян маймыллар һәм авыр гәүдәле крокодиллар, бөтерчек суалчаннар һәм курку белмәс борындыклар, авыр гәүдәле жирафлар һәм мырлый торган песиләр була.  Шушы көндә Аллаһы тарафыннан төрле токымдагы хайваннар булдырыла.  Кич була да таң ата – алтынчы көн китә.



Алтынчы көнне Аллаһы гадәти булмаган, бик тә үзенчәлекле бер әйбер ясый. Кешелек өчен инде барысы да әзер була.  Аңа хезмәт итү өчен кырларда ашлык һәм җанварлар бар.  “Кешене Үз сурәтебездә, Үзебезгә охшатып яратачакбыз… җир өстеннән хакимлек итсен!” – дип әйтә.  ШУЛАЙ ИТЕП, АЛЛАҺЫ КЕШЕНЕ ҮЗ СУРӘТЕНДӘ, АЛЛАҺЫГА ОХШАТЫП ЯРАЛТА …



Раббыбыз Адәм
белән сөйләшә.
“Бакчадагы теләгән
һәр агачның
җимешен ашарга
рөхсәт, әмма
яхшылыкны
һәм яманлыкны
таныта торган белем
агачыннан ашама,
чөнки ул агачның
җимешен ашаган көнне
үк мотлак үләчәксең”.



Соңра Раббы Алла: “Адәмне ялгызын калдыру әйбәт түгел, үзеңә тиң бер ярдәмчене ярачакмын”, - дип әйтә. Раббы Алла җирдәге хайваннарның, күктәге кошларның барчасын да Адәм хозурына чакырып китерә. Адәм аларның барысына да исем кушып чыга. Болай эшли белгәч, мөгаен, ул бик акыллы булгандыр. Ләкин бу кошлар һәм хайваннар арасында аңа тиңдәш булырлык бер генә ярдәмче дә табылмый.



Раббы Алла Адәмне бик тирән йокыга талдыра.  Адәм йоклап киткәч, аның бер кабырга сөяген суырып алып, шул кабырга сөягеннән бер хатын-кызны яралта һәм аны Адәм хозурына китереп бастыра.



Раббыбыз дөньяны алты көндә бар итә. Шуннан җиденче көнне Ул мөбарәк кыла һәм бу көнне ял итә.  Гадән бакчасында Адәм дә, аның хатыны Һава да, Аллаһы сүзеннән чыкмыйча бик бәхетле булып тереклек итә.  Аллаһы – аларның Раббысы, тукландыручы

һәм дус була.



# Аллаһы дөньяны кайчан бар иткән

Аллаһы Сүзеннән, Изге Язмадан хикәят

урнашкан

Яратылыш 1-2

“Сүзләреңнең күренүе балаларны яктыртып акыллыландыра.” Мәдхия 119:130

# Тәмам

1

60

Әлеге Изге Язма хикәятендә Җир йөзендәге барча тереклекне бар кылган һәм Үзенә иман китерүебезне теләгән кодрәтле Аллаһы турында бәян ителә.

Раббыбыз начар гамәлләр кылуыбыз турында белеп тора, Ул аларны гөнаһ дип атый. Гөнаһның җәзасы – үлем. Ләкин Аллаһы сезне шулкадәр ярата ки, гөнаһларыгыз өчен җәзаланырга дип бердәнбер Улы Гайсәне хачта үтертү өчен җибәрде. Шуннан соң Гайсә үлеп терелде һәм Күккә ашты! Гайсәгә ышансагыз, гөнаһларыгызны кичерүе турында сорагыз, Ул моны эшләр! Ул килер һәм сездә яшәр, һәм сез дә мәңге Аның белән бергә булырсыз.

Моның хак булуына ышансагыз, Аллаһыга болай диегез: Хөрмәтле Гайсә, Синең Раббы булуыңа һәм гөнаһларым хакына һәлак ителү өчен кеше булып яралтылуыңа һәм хәзерге вакытта исән булуыңа ышанамын. Зинһар өчен, тормышыма үтеп кер, мин яңа тормыш башлап, кайчан да булса Синең белән мәңге бергә була алсын өчен, гөнаһларымны ярлыка. Балаң күк, Сиңа сәҗдә кылып, Сиңа иман китереп яшәргә ярдәм ит. Амин.

Изге Язма укы һәм көн саен Аллаһы юлында бул! (Яхъя 3:16)